وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

**№6 (149). 10 август 2012 / 22-рамазан-1433**

**ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ**




Фитыр сәдакасы

▷2◁



Мифтахетдин Акмулла иҗатында Аллаһы атамасының кулланылышы

▷3◁



Миңа ирем белән мөселманнар булмаган мохиттә яшәве кыен...

▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

### ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ “ТУГАН АВЫЛЫМ”ДА ИФТАР АШЫ ҮТКӘРДЕ

**8 августта ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм ярдәм күрсәтү бүлеге Дәрвишләр бистәсендәге интернат-йортта тәрбияләнүче физик тайпылышлары булган сабыйлар өчен ифтар мәҗлесе оештырды. Әлеге чара “Туган авылым” ресторан-күңел ачу үзәгендә үтте. Балалар өчен мультфильм геройлары тарафыннан махсус күңел ачу программасы әзерләнгән иде. Сабыйлар үзләренең осталыкларын төрле уеннарда, бәйгеләрдә күрсәтте, оештыручылар һәрберсенә дә истәлекле бүләкләр тапшырды.**

– Дәрвишләр бистәсендәге әлеге интернат-йорт белән быел гына хезмәттәшлек итә башладык. Сабыйларга карап, һәрбер кеше үзенең тормышы турында уйлана һәм билгеле бер нәтиҗәләр ясый ала. Шунысы куанычлы: мондый төрдәге изге гамәлләрне оештыруга яшьләр дә битараф түгел. Бүгенге ифтар мәҗлесен оештыруда да яшьләребез үзләреннән зур өлеш кертте, кайбер финанс чыгымнарын үз өсләренә алды. Ә сабыйларга килгәндә, биргән бүләкләр, уеннардан гына түгел, хәтта җылы караш, бер елмаюдан да аларның кәефләре күтәрелә. Шуңа да Рамазан аенда гына түгел, һәр көнебезне, һәр гамәлебезне игелек кылуга багышласак иде. Сентябрь аенда Дәрвишләр бистәсенә үзебез барырга ниятлибез, – дип билгеләп үтте ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге җитәкчесе Гөлнара Садыйкова.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте “Туган авылым” ресторан-күңел ачу үзәге җитәкчесе Натиг Бадаловка әлеге ифтар мәҗлесен оештыруда катнашканы, гомумән, хәйрия ашын тулаем үз өстенә алганы өчен зур рәхмәтен җиткерә. Киләчәктә дә бердәм хезмәттәшлеккә өметләнеп калабыз. Аллаһы Тәгалә кылган изге гамәлләрен үзенә меңе белән кайтарса иде.

### КАЗАН УРАМНАРЫНДА СОЦИАЛЬ РЕКЛАМА БАРЛЫККА КИЛДЕ

**Изге рамазан ае уңаеннан Казан урамнарында башкалабызда яшәүчеләргә рухи кыйммәтләрне җиткерә торган социаль реклама барлыкка килде.**

ТР мөселманнары Диния нәзарәте Казан шәһәре хакимияте ярдәмендә башкалабыз урамнарына изге рамазан ае белән котлап баннерлар урнаштырды. Элмә такталарга “Рамазан ае мөбарәк булсын!” дигән котлау сүзләреннән тыш, игелекле, мәрхәмәтле булырга өнди торган Коръән аятьләре дә язылган.

Рамазан уңаеннан ике дәүләт телендә эшләнгән социаль элмә такталар башкалабызның халык күп йөри торган урыннарына киләсе елларда да куелыр дип көтелә. Белгәнебезчә, быел мондый төр эчтәлекле баннерлар Түбән Кама шәһәре урамнарын да бизәп тора.

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ! Һәр айның 24 нче числосына кадәр почтага барып “Дин вә мәгыйшәт” газетасына язылсагыз, ул сезгә киләсе ай башыннан килә башлаячак.**

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

# КАДЕР КИЧӘСЕ

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим! Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһү, хөрмәтле татарстанлылар!**

Менә инде изге Рамазан аеның да санаулы көннәре калып килә. Аның ахыргы ун көне һәр мөселман кешесе өчен аеруча кадерле вә кыйммәтле: Кадер кичәсенең ("кодрәт һәм язмыш төне") нәкъ менә шул төннәргә яшерелгән булуы мөмкин. Бу көнне, иң әүвәл Ләүхүл-Мәхфүздә язылган Коръән күкнең түбән катламнарына төшерелгән, аннан соң Җәбраил фәрештә Аллаһы Тәгаләнең кушуы буенча аны 23 ел дәвамында Пәйгамбәребезгә (сгв) җиткергән. Безнең барыбызга да Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) болай дип әйткән хәдисе билгеле: "Сез Кадер кичәсен рамазан аеның соңгы ун көненең так төннәреннән эзләгез". Гайшә анабыз (Аллаһ аннан разый булса иде) җиткергән: "Рамазанның соңгы төннәрендә Пәйгамбәр йокламады һәм үзенең барлык якыннарын да әлеге төннәрдә Аллаһка бирелеп гыйбадәт кылырга өндәде".

Кадер кичәсе - дәрәҗә һәм мәртәбә төне. Бу төндә язмышлар, гамәлләр, дөнья кыйммәтләре хәл ителә. Әгәр дә төннең




Аллаһка гыйбадәт кылып җанланып китүе Кадер кичәсе белән туры килә икән, Аллаһның бүләкләве безнең бу төнгә хас аерым билгеләрне күрү-күрмәвебезгә бәйле булмаячак. Әбү Һөрәйрәнең сүзләреннән Пәйгамбәребезнең болай дип әйткәнен җиткерәләр: "Ләйләтүл-Кадер төнен Аллаһның бүләгенә өмет итеп һәм шуңа ышаныч белдереп үткәргәннәрнең моңа хәтле кылган гөнаһлары ярлыканыр". Икенче бер хәдистә әйтелә: "... аның соң эшләнәчәк гөнаһлары да ярлыкана".

Коръәндә Ләйләтүл-Кадер төненә тулы бер сүрә багышланган - 97 нче сүрә - "Кадер" сүрәсе. Әлеге төндә игелек-иминлек бирүче һәм аны өләшүче фәрештәләр җиргә төшәчәкләр, ә шайтан чылбырга богаулап куелачак һәм беркемгә дә зыян сала алмаячак. Төн "язмыш хәл ителү төне" дип атала, чөнки бу төндә киләсе елның Кадер кичәсенә кадәр бар тереклеккә яшәү өчен кирәк булган нәрсәләр тәкъдир кылына. Бу төндә шулай ук түбәндәге эчтәлекле дога кылу мәслихәт: "Әй Аллам! Син Гафу итүче. Син Гафу итәргә яратасың. Гафу ит мине, гөнаһларымнан ярлыка!"

Төнге гыйбадәтләрнең дәрәҗәсе турында күп кенә аятьләр бар һәм бу турыда бихисап хәдисләр китерелә. Әлеге хәдисләргә нигезләнеп, Мостафа Мөхәммәд Гаммәрәт "Әт-тархибә" хикәятендә болай дип яза: "Төнге гыйбадәтләр калебне һәм күзләрне тынычландыра, җанга рәхәт булып китә, иблиснең төене чишелеп, гыйбадәт кылу өчен тән җиңеләя. Төнге гыйбадәт Җәннәткә юл сала, Җәһәннәмнән саклый, Кыямәт көненең Гарасат мәйданында сорау алу кыенлыгыннан азат итәчәк. Әгәр дога кабул ителү вакытына туры килә икән, теләкләр чынга аша. Төнге гыйбадәтләр сәламәтлекне һәм күрү сәләтен яхшырта, авырулардан ерагайта.

Төнне гыйбадәттә үткәрү кешенең дәрәҗәсен күтәрә, Аллаһы Тәгалә ул кешегә шәфкать, мәрхәмәт белән караячак, ул Аллаһның күләгәсендә булачак, эшгамәлләрдә уңышка һәм бәхеткә ирешер, Аллаһ аны начарлыклардан саклаячак, һәм аңардан курку тойгысы юкка чыгар".

Барлык мөселманнарга да әлеге төннәрне гыйбадәттә үткәрү өчен Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә көч-куәт бирсә һәм догаларыбызны кабуллардан кылса иде.

**Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһү!**


**Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**


# Кадер кичәсе мең айдан да хәерлерәк

**Әлхәмдүлилләһи раббил галәмиин. Вәл гакыйбәтүлил мүттәкыйн. Вәссаләтү вәссәләәмү галә Мүхәммәдин вә галә әлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Барлык мактауларыбыз галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Рәсүлебезнең (сгв) рух-шәрифенә дип атап әйткән салават-шәрифләребез булса иде. Һәм дә иң беренче Адәмнән (гс) алып, бүгенге көнгә хәтле килеп киткән барлык мөэмин вә мөэминәләрнең дә рух-шәрифләренә дип кылган изге догаларыбыз булса иде.**

**КАДЕР** төне кайчан соң ул? Аны кайсы төннән эзләргә? Кайбер галимнәр әйтә: ул - Рамазанның 21 нче төне, икенчеләре - 23 нче төне, өченчеләре - 25 нче төне, ә күпчелек галимнәр - ул 27 нче төн, диләр. Пәйгамбәребез (сгв): "Кадер кичәсен Рамазанның ахыргы ун төненең так төннәрендә эзләгез", - диде.

Рамазан аеның соңгы ун төне башка төннәрдән, кадерле вә әҗерле, фазыйләтле Кадер кичәсе булуы белән аерылып торудан гыйбарәт. Раббыбыз үзенең Китабында Кадер кичәсе турында аерым бер сүрә дә иңдергән: "Иннәә әнзәлнәһү фи ләйләтил Кадр. (Хакыйкать шулдыр ки, Без аны (Коръәнне) Кадер кичәсендә иңдердек.) Вә мә әдракә мә ләйләтуль Кадр. (Кадер кичәсенең нәрсә икәнен сиңа аңлатучы булдымы?) Ләйләтуль Кадери хайрум мин әлфи шәһр. (Кадер кичәсе мең айдан да хәерлерәк.) Тәнәззәлүл мәләикәтү вәр-руху фиихә биизни раббихим мин күлли әмр". (Ул көндә фәрештәләр вә Изге Рух (Җәбраил), Раббының рөхсәте илә, Аның әмерләрен җиренә җиткерер өчен, бер-бер артлы иңеп кенә торырлар.) Сәләмүн һия хәттә мәтләгыль фәҗер.(Кадер кичәсе - иминлек кичәсе - таң ата башлаганга чаклы дәвам итәр.)" Дөрестән дә, ибне Габбас әйтә: "Раббыбыз Коръәнне Кадер кичәсендә Ләүхүл мәхфүздән алып дөнья күгенә иңдерде". Соңрак егерме өч ел дәверендә Җир йөзенә кисәк-кисәк иңдерде, ди.

Кадер дигән сүз - ул кодрәт дигәнне аңлата. Икенче мәгънәсе - тәкъдир. Бу кичәдә фәрештәләр адәм баласының бер еллык тәкъдирен алып киләләр. Кадер төне мең айдан да кадерлерәк. Ул төнне догада, гыйбадәттә, зекердә, намазда үткәргән бәндә мең ай гыйбадәт кылудан да зуррак әҗер алачактыр. Рәсүлебез (сгв) әйтә: "Кем дә кем Кадер кичәсен уяу үткәреп гыйбадәттә булса, бу кичәдән чыкканда әнисеннән туган сабый бала кебек гөнаһсыз чыгар", - ди. Аллаһы Тәгалә: "Кадер кичәсе мең айдан да хәерлерәк", - ди.

Мең ай ул 83 елдан да артык бит, кардәшләрем! Бу бер кичәдә 83 елдан да күбрәк гыйбадәт кылдың дип әҗер бирелә, бу шатлык түгелмени? Кадер төне тынычлык, иминлек кичәседер. Җир йөзенә килгән фәрештәләр иминлек,тынычлык белән киләләр. Алар күбрәк гыйбадәт кылучылар белән бергә булырлар, ди. Ул кичәдә шайтан да үзенең мәкерлеген кыла алмас. Гайшә анабыз Пәйгамбәребездән (сгв) сорады: "Йә рәсүлебез, әгәр мин Кадер кичәсенә ирешсәм, миңа ничек дога кылырга?" - диде. Рәсүлебез (сгв) әйтте: "Аллаһүммә иннәкә гафуун түхиббүл гафвә фәгъфу ганни. (Әй Аллам, Син гафу итүче, Син гафу итәргә яратасың - гафу ит мине, гөнаһларымны ярлыка), - дип дога кыл", диде.

Кадер төненең үзенә генә хас булган галәмәтләре бар. Ул башка төннәрдән аермалы буларак, яктырак, нурлырак булыр. Кадер төне бик тыныч, җилсез, матур, имин булыр. Ул төнне артык эссе, я артык салкын да булмас. Җирлектәге табигать күрсәткечләренең уртачасы булыр. Кадер кичәсендә йолдызлар

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# Кадер кичәсе мең айдан да хәерлерәк

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

да атылмас. Кадер кичәсеннән соң килгән көннең кояшы артык якты булмас, чөнки ул көнне шайтанга кояш белән бергә торырга мөмкин булмас. Йә Раббым, безнең Пәйгамбәребез (сгв) зур тырышлыклар куйган кичәләрдә безгә дә уяу торып, гомеребезне заяга уздырмыйча, Кадер кичәләренә гафил булмыйча, Раббыбыздан безгә бирелгән бу форсатлардан файдаланып, бу рәхмәтләрен кулланып, Аллаһның рәхмәтенә ирешергә насыйп итсәң иде.

Изге рамазан ае җитсә, Раббыбыз үзенең бәндәләренә игелек кылырга Үзе ярдәм итә. Рамазан аенда бөтен җәннәт ишекләре ачык, шайтаннар да башка айлардагы кебек тәэсир итә алмыйлар, алар да богауларда, җәһәннәм ишекләре дә ябылган, ничек инде изгелеккә омтылмаска?! Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Изге рамазан ае җитү белән, бөтен җәннәт ишекләре ачылыр, берсе дә ябылмас, бөтен җәһәннәм ишекләре ябылыр, берсе дә ачылмас вә бөтен шайтаннар богауларга богауланыр", - ди. Икенче бер хәдисендә Рәсүлебез (сгв) шулай ук: "Изге рамазан ае җиткәч, күктә тавыш килер. Фәрештәләр әйтерләр: "Әй начарлыкка омтылучы, начарлык кылучы, туктат начарлыгыңны, Рамазан җитте, әй изгелеккә омтылучы, ашык, кабул итеп ал, Рамазан җитте. Бу кичәдә көн саен җәһәннәмнән котылучылар булыр". Әй Раббым, безне дә бу айда җәһәннәм утыннан котылучылар җөмләсеннән кылсаң идең, ахирәттә җәннәтең белән шатланучылардан булырга насыйп әйләсәң идең.

Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Адәм баласы Рамазан аенда кылган гыйбадәтләре өчен башка бер айда да алмаган әҗер-саваплар ала. Бер кылган сөннәт гамәл өчен фарыз гамәлгә бирелгән савап бирелә, ә кем бер фарыз гамәлен кылса, 70 фарыз гамәл кылган әҗерен алыр", ди. Хөрмәтле җәмәгать, карагыз, бер сөннәткә күпме әҗер бирелә. Карагыз, бер кылган фарыз гамәлгә күпме фарыз гамәлләр кылды, дип язылыр! Бу рамазан аенда Аллаһның рәхмәте никадәр зур.




Пәйгамбәребез (сгв) турында килгән хәбәрләрдән: "Дөрестән дә, рәсүлебез кешеләрнең иң юмарты иде, ә иң юмарт вакыты Рамазан башлангач була иде". Ибне Габбас (рг) әйтә: "Пәйгамбәребез иң юмарт кешеләрдән иде вә Рамазан башланса аның иң юмарт вакыты башлана иде", ди. Гайшә анабыз әйтә: "Рәсүлебез иң юмарт кешеләрдән иде. Иң юмарт вакыты Рамазанда башлана иде, һәр богаулыны азат итә иде вә һәр сораучыга бирә иде", ди.

Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Аллаһ юмарт вә юмартлыкны сөядер", - ди. Сәхабәләр әйтәләр: "Пәйгамбәребез нихәтле генә юмарт булмасын, аның юмартлыгы барыбер Рамазанда арта иде", - диләр. Пәйгамбәребез (сгв): "Иң хәерле сәдака - ул да булса, Рамазан сәдакасыдыр", - ди.

Рамазан юмартлыгына тагын бер дәлил - ул да булса, кешеләрне авыз ачтыру, ифтарлар үткәрү. Пәйгамбәребез (сгв): "Кем дә кем ураза тотучыны авыз ачтырса, шул кеше күпме ураза тотучыны ашаткан булса, аларның бөтенесенең дә әҗерләрен үзенә алыр, шуның өстәвенә ураза тотучыларның да әҗерләре кимемәс", - ди. Рамазан аенда ураза тотучыны авыз ачтырсаң, ул синең гөнаһларыңа каффәрәт булып, уттан котылуыңа сәбәп булыр, ди пәйгамбәребез. Сәхабәләр Пәйгамбәребезнең (сгв) бу сүзләрен ишеткәч бик тәэсирләнделәр, тик бөтенесенең дә авыз ачтыртып ураза тотучыларны ашатырга хәленнән килми иде, моны алар Пәйгамбәребезгә (сгв) җиткерделәр. Рәсүлебез (сгв) аларга әйтте: "Нияте изгедә булып ураза тотучыны бер хөрмә яки бер йотым су белән булса да авыз ачтырсагыз, сез шундый ук әҗер алырсыз, бу изге эшегез өчен Раббыгыз сезне Кыямәт көнендә шундый су эчерер, бәндәнең җәннәткә кергәнчегә хәтле башка бер дә эчәсе килмәс", - диде. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, белегез, бу изгелек айларында да безгә бирелгән форсатлардан файдаланып калмасак, ахирәткә баргач ничек иттереп җавап бирербез икән?!

Мәдинә шәһәрендә Гали (рг) вафат булгач, аның бөтен җилкә башларының фәкыйрьләргә он ташудан суелып беткәнен күрәләр. Шуннан соң инде бу сәхабәнең кешеләрдән яшереп ятимнәргә сәдака биргәнен аңлыйлар. Шайтан безгә әйтә: "Сәдака бирмә, әгәр бирсәң фәкыйрьләнерсең", - ди. Пәйгамбәребез: "Сәдака малны киметмәс, - ди. - Юмартка Аллаһы Тәгалә малны арттырып бирә вә сараннан каерып алыр".

Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Көн саен иртә белән Җир йөзенә ике фәрештә төшә вә ике дога кылалардыр, йә Раббым, бирүчегә бирсәң идең, диләр; икенче догалары - йә Раббым, саранныкын тартып алсаң идең, диләр".

Раббым, барыбызны да юмарт куллы вә киң күңелле итсәң идең. Пәйгамбәребез (сгв) кебек юмарт булып ахирәттә дә әҗерләрен күреп юмартлар арасыннан безне кылсаң идең.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Пәйгамбәребезнең (сгв) сәхабәләре бездән зирәк, бездән иманлы, бездән галим вә тырыш булдылар. Сәхабәләр рамазан аена ярты ел вакыт калгач Раббыбызга дога кылалар иде: "Йә Аллаһ, безне рамазан аена җиткерсәң иде, безне саусәламәт рәвештә шул хәерле айларда ураза тотарга насыйп әйләсәң иде, безне фетнәләрдән саклап, төннәрен уяу торып, бу айларда гөнаһлардан котылырга ярдәмеңне бирсәң идең".

Рамазан аенда көннәребезне заяга уздырмыйча, биргән нигъмәтләрдән файдаланып, изгелекләр кылып җәннәтләрдә дә бергә булырга насыйп булса иде.

**Алмаз хәзрәт ШӘРИФУЛЛИН,**
**Татарстанның көньяк төбәге казые,**
**Чистай районы имам-мөхтәсибе**

---

# Фитыр сәдакасы

**ФИТЫР СӘДАКАСЫН КЕМНӘР ҺӘМ КЕМНӘР ИСӘБЕННӘН БИРҮ ТИЕШЛЕ?**

*Фитыр сәдакасы безнең өммәтебезгә хас үзенчәлек булып тора. Ул Һиҗринең икенче елында - Ураза бәйрәменә ике көн кала мәҗбүри булган. Аллаһы Тәгалә тарафыннан үтәлергә кушылган әлеге гыйбадәтнең хикмәте шунда ки, әлеге сәдаканы түләү белән без ураза вакытында җибәрелгән хата-кимчелекләребездән һәм ялгышлыкларыбыздан азат булырбыз, Иншә Аллаһ.*



Әнәс бине Мәликтән килгән хәдистә болай диелгән: **"Рамазан уразасы җир белән күк арасында эленеп тора, һәм фитыр сәдакасын биргәннән соң гына ул күкләргә ашачак" (Имам Дайлами).**

Фитыр сәдакасын мөселман булмаганнардан һәм фәкыйрьләрдән тыш, бар кеше дә бирергә тиеш. Мөселман булмаганнар үзләре өчен бу сәдаканы бирергә тиеш булмасалар да, алар үзләре карамагында булган мөселманнар өчен аны түләргә тиеш.

**Фәкыйрьләр** - үзләренә һәм гаиләләренә ашарга ризыклары җитмәгән кешеләр. Ризык бер бәйрәм көненә җитәргә тиеш (бәйрәм табыны исәпкә алынмый). Тиешле ризык күләме һәр гаилә әгъзасына 1 мүдд ярма хисабыннан исәпләнә (1 мүдд = 650 грамм). Әгәр дә кеше фатирга кереп яшәгән өчен түли икән, бу йортта яшәп торырга кирәк булган акчадан фитыр сәдакасы түләнми. Караучысыз йөри алмаган һәм табиблар ярдәменнән башка тора алмаган сырхау кешеләр - табибларга, караучы хезмәтенә һәм дарулар өчен түләргә тиеш булган акчадан фитыр сәдакасы түләмиләр. Бурычлары булган кешеләр, әгәр дә бурыч түләүне кичектереп тора алалар икән, фитыр сәдакасын бирергә тиешләр.

Фитыр сәдакасы түләүнең шартлары: мөселман булу; рамазан һәм шәүвәл айларында исән-сау булу. Рамазан аеның соңгы көнендә кояш баегач вафат булган кеше өчен фитыр сәдакасы бирелә, ә кояш батканчы үлгән кеше өчен бирелми. Рамазан аеның соңгы көнендә туган һәм кояш баеганчы исән булган бала өчен дә фитыр сәдакасы түләнә.

Фитыр сәдакасын гаилә башлыгы барлык гаилә әгъзалары һәм аның тәрбиясендә булган кешеләр өчен үзенең кеременнән түли.

Ире фәкыйрь булса яки эшләмәсә, ә хатыны бай булса яки эшләсә, ул үзе, ире һәм аның тәрбиясендә булганнар өчен фитыр сәдакасын бирә ала, әмма мәҗбүри түгел. Бу - хатын-кыз өчен сөннәт тә түгел. Ул теләге буенча үзе өчен генә яки гаиләнең бер әгъзасы өчен генә дә түли ала. Әгәр дә аерган хатыны йөкле икән, ире аның өчен зәкят түләргә тиеш, чөнки ул бала туганчы хатынын тәэмин итеп торырга (тәрбияләргә) тиеш.

Тол хатыннар һәм аерылганнар өчен фитыр сәдакасын опекуны (кемне дә булса опекага алган кеше) түләргә тиеш. Әгәр дә опекуны булмаса, үзе түли. Балалар өчен фитыр сәдакасын түләү бурычы аларның аталары яки гаиләдәге башка ир-атлар өстендә. Алар бу бурычны үтәмәгән очракта да, фитыр сәдакасын балалар өчен хатын-кыз түләргә тиеш түгел.

Балигъ булмаган балаларның үз кереме булса да, алардан зәкят түләнми.

Ир бала балигъ булуга, ул үзе өчен фитыр сәдакасын үз кеременнән түләргә омтылырга тиеш. Андый мөмкинчелеге булмаган очракта, бу бурыч гаиләдәге башка ир-атлар өстенә төшә.

Хатын-кызның һәм аның балаларының опекуннары булмаган очракта, бу бурыч аның балигъ булган һәм эшли башлаган өлкән улына йөкләнә.

**ФИТЫР СӘДАКАСЫН КЕМНӘРГӘ БИРЕРГӘ?**

Зәкятне үзең белән бер җирлектә яшәүче кешеләргә таратырга кирәк. Шул җирлектә зәкят таратылырга тиешле кешеләр булмаса гына башка җирлектә таратыла ала. Имам киңәше белән башка авылга да күчерергә мөмкин.

Фитыр сәдакасын 8 төр кешеләргә бирергә була. Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә аларны санап үтә: "Сәдака (зәкят) Аллаһтан бер фарыз буларак, бары тик юксылларга, мескеннәргә, (зәкят эшләрен башкаручы) йомышчыларга, күңелләре (Исламга) ятканнарга, (ирекkә чыгу өчен җан аткан әсирләргә) колларга, бурычка батканнарга, Аллаһ юлында көч сарыф итеп, җиһадта катнашканнарга, юлчыларга бирелергә тиеш. Аллаһ барысын да бик яхшы белеп торучы һәм хикмәтләр ияседер". ("Тәүбә" сүрәсе, 60 нчы аять).

**ФИТЫР СӘДАКАСЫН АЛЫР ӨЧЕН АЛАР ТҮБӘНДӘГЕ ШАРТЛАРГА ТУРЫ КИЛЕРГӘ ТИЕШЛӘР:**

1. Ирекле (азат) һәм мөселман булырга.
2. Мотталиб һәм Хашимит нәселен дәвам иттерүчеләр булмаска тиеш.
3. Үз акылында һәм балигъ булырга. Имам Нәвави исә балигъ булып та, намаз укымаган кешегә сәдака бирергә рөхсәт итмәгән, бары тик аның опекунына бирергә кушкан. Балалар һәм үз акылында булмаган кешеләргә биреләчәк сәдака белән дә эшне шулай хәл итәргә кирәк. Әгәр дә опекуны булмаса, ул барлыкка килгәнче зәкят түләнми. Ләкин балигъ булгач намаз укый башлаган, соңрак аны ташлаган кешегә сәдака бирелә. Фасыйкларга, әгәр дә алар аның ярдәмендә гөнаһ эшләр кылмыйлар икән, шулай ук сәдака бирелә ала.
4. Сәдака алучының сәдаканы бирүче тәрбияләргә тиеш булган кеше булмавы (ата-анасы, балалары һ. б.) шарт. Бу фитыр сәдакасы булып саналмый, чөнки без аларны болай да карарга тиеш.

Башка кешенең ата-анасы һәм балаларына сәдака бирү мәсьәләсенә килгәндә, ике шарт бар: әгәр дә аларга опекуннары биргән җитсә, фитыр сәдакасы бирелми, җитмәсә - бирелә, чөнки бу очракта алар фәкыйрьләр рәтенә керә. Фитыр сәдакасын сез тәрбияләргә тиеш булмаган туганнарыгызга бирү хәерлерәк. Бу - әгәр дә алар зәкят тапшырыла ала торган кешеләр исәбенә керә икән - энеләр, сеңелләр, абыйлар, апалар һәм аларның балалары һ. б.

**Исегезгә төшерәбез: быел ТР мөселманнары Диния нәзарәте фитыр сәдакасының иң аз күләмен (ашлык бәясеннән чыгып исәпләгәндә) 50 сум, дип билгеләде. Урта хәлләр өчен - 100 сумнан алып 300 сумга кадәр (хөрмә һәм йөзем бәяләре буенча).**

---

**Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛИН:**

# "Рамазан ае зур активлык белән үтә"

***Быелгы рамазан ае Чаллы шәһәре мөселманнары тормышында нинди эз калдыра? Ошбу сорауга шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин болай дип җавап бирде:***

- Быелгы Рамазанга озын һәм кызу көннәр хас булса да, үткән еллар белән чагыштырганда ураза тотучылар, тәравих намазында катнашучылар саны кимемәде. Киресенчә, яшьләр һәм мәктәп яшендәге балалар исәбенә күбәя төште. Чөнки менә инде берничә ел изге аебыз балаларның җәйге каникулы чорына туры килә. Тәравих намазларының төнге унберенче яртыда башланып уникенче яртыда тәмамлануы да балаларны куркытмый.

Барлык мәчетләребездә дә ифтарлар узды. Ак мәчеттә, "Ихлас"та, "Тәүбә"дә алар һәр көнне оештырыла. ГЭС мәчетендә көн аралаш үткәрелә. Шулай ук шәһәребездәге хәләл кафеларда да авыз ачтыру мәҗлесләре булып тора. Дүртенче ел рәттән шәһәр күләмендә ифтар уздырырга ниятлибез - шәһәр башлыгы, мөфти хәзрәт һәм шәһәрнең мөселман активы катнашында. Быелгы чарабызда мөфти вазифаларын башкаручы Габдулла хәзрәт Әдһәмов катнашыр дип уйлыйбыз. Аның белән бу темага сөйләшү булды инде. Бу көнне шәһәр мәчетләрендә, кафеларда да ифтарлар узачак. Бәлкем киләчәктә, Аллаһ насыйп итсә, зуррак масштабта да оештырырга мөмкин булыр.

Шәһәребезнең төп проспектларында рамазан аена багышланган баннерлар эленеп тора, алар халыкка изге ай турында исләренә төшерә. Шәһәребезнең "Күңел" радиосыннан һәр көнне имамнарыбыз вәгазьләр сөйли, сорауларга җаваплар бирә. "Чаллы-ТВ" да иртәдән кичкә кадәр ураза хакында искәртеп тора, сәхәр, авыз ачу вакытларын хәбәр итә. Шәһәр хакимияте булсын, предприятиеләр булсын - безнең әйткән сүзләребезгә һәркайсы игътибарлы.

Һәрбер мәчеттә Коръән чыгыла. Бу изге гамәлне башкаруга Төркиядән килгән хөрмәтле кунагыбыз Коръән-хафиз Сәлмән хәзрәт Узунлы да зур өлеш кертә. Ул мәхәлләләрдә тәравих намазлары укыта, ифтарларда Коръән укый, кыска гына вакытка булса да хәзрәтләребезне ял иттерә.

Рәсемнәрдә: шәһәрнең 27 нче бистәсе - "Сөембикә" мәхәлләсендә төзелүен дәвам итүче, әле ишек-тәрәзәләре дә булмаган мәчет бинасында зур ифтар мәҗлесе; Нур-Ихлас мәчетендә тәравих намазы; Коръән-хафиз Сәлмән хәзрәт.

**Материал Чаллы мөхтәсибәте белән берлектә әзерләнде**



# Мифтахетдин Акмулла иҗатында Аллаһы атамасының кулланылышы

**Классик иске татар телендә иҗат итүче шагыйрьләребезнең әсәрләрендә, XVIII йөздәге кебек үк, XIX гасырда да, гарәп-фарсы алынмалары, шул исәптән Аллаһы атамасы да, эзлекле кулланыла. Бу сүзләр, сәнгатьле фикерне укучыга үтемлерәк итеп җиткерү максатыннан, төрки-татарның үз сүзләре белән бер дәрәҗәдә диярлек, тасвирый чара буларак файдаланыла. М.Акмулланың Казан университеты типографиясендә 1892 елда басылган "Дамелла Шиһабетдин хәзрәт мәрсиясе"ндә әлеге үзенчәлек ачык чагыла. Акмулланың иҗатын җентекләп тикшерүче галим М.Госманов билгеләгәнчә, "Татар, казакъ һәм башкорт телләренең җанлы хәзинәсеннән виртоуз дәрәҗәдә җиңел файдалана алган шагыйрь классик язма татар теленең бөтен нечкәлекләрен, иңләнмәгән лексик байлыгын үз ихтыярына теләгәнчә буйсындыру көченә ия булган".**

Шагыйрьнең бу үзенчәлеге, асылда, бер үк төшенчәне берничә төрле сүз һәм сүзтезмәләр белән исемләп тәгъбир итүдә күренә. Автор Ш.Мәрҗанинең һәрьяклап килгән галим, акыл иясе, остаз булуын сурәтләгәндә, аны фазыйл, камил, асыл ир, ир булган ирән, гали галим дип берничә мәртәбә кабатлагач, шул үк төшенчәне тагын сүзнең күпмәгънәлегенә нигезләнгән Мәрҗани - ул Тимерказык, ...Һавада ул бер шоңкар - әйләнә очкан кебек сүз-сурәтләр белән тасвирлауны дәвам итә. Мәрсия өлешендә әлеге чагыштырулар тагын да куәтлерәк бирелә: Мәрҗани ислам шәригатен нигезләүче дүрт имамның берсенә һәм зирәклеге белән дан тоткан пәйгамбәргә, юлбашчы-солтанга һәм кояш белән былбылга тиңләштерелә: Фикъһедә бу заманның Ногманы бу, Хикмәттә бу заманның Локманы бу. ...Әһле сөннәт рәһбәре-солтаны бу! Менә шул рәвешле, Мәрҗани - бөек галим дигән фикерне Акмулла ике дистәгә якын сүз һәм сүзтезмәләре белән исемләп тасвир итә.

Шушы ук ысул белән, әсәр эчтәлегендә, Аллаһы, Хак-хакыйкать төшенчәләре дә когнитив-семантик үсештә бирелә. Аллаһы Тәгаләнең исемен шагыйрь Иляһи, Ходай, Раббе, Тәңре сүзләре белән чиратлаштырып куллана. Шуның белән бергә тагын Аллаһы Тәгаләнең Рахим, Җәббар, Гаффар, Галим, Кәрим, Хаккъ, Малик, Зөл-Җәлали кебек Исме-Әгъзам күркәм исемнәрен файдалана. Бу атамалар сүз-лексема буларак: Ходай, Хода, Раббе, Иляһ һ. б., төрле Иляһи шәкел-формулалар рәвешендә: Хәмдулиллаһ, Иншаллаһ, Бәрәкаллаһ, Бисмиллаһ һ. б., төрле исем-атамаларның бер компоненты буларак: Рәхмәтулла, Мохибулла, Рәсүлуллаһ, Рәхимуллаһи, Сәкыйуллаһ, Кәлимуллаһи һ. б. Сан ягыннан караганда, әлеге исемнәр тотрыклы һәм ирекле сүзтезмәләр составында күбрәк файдаланыла: Иннәма йахшия Аллаhе, Ходай боерса, Аллаһы колы, бирмәсә Ходай, Тәңре алдына бару, Ходайдан оялмаса, мәгаз Аллаһ, Ходай кичәр, Аллаһудан курку, Ходай рәхмәте, Ходай өчен, Ходага ярарлык, Ходадан теләү, Ходаның кылганы, Ходаның язганы, Хакъ багың, Хода кичер, Ходай ору, Аллаһыны тану һ. б. Күренгәнчә, бу төр тезмәләрдә Ходай һәм Хода исемнәре ешрак кабатлана. Ходай сүзе тагын I зат берлек сандагы тартым кушымчасы алган хәлдә дә эзлекле файдаланыла: Ходаем фирасәтле йөрәк биргән, Ходаем фөсәханың замирендә, Ходаем тәүфыйк биреп күндермәсә, Ходаем кылган эшкә чара бармы? Хакъ әсәде - бер Ходаем аралаган, Ходаем бу дөнйада ормайды икән һ. б.

Аллаһы төшенчәсен белдерә торган атамалар парланып та кулланыла. Мәсәлән, Ходай сүзе Аллаһның бик көчле, бик куәтле, зур көч иясе икәнлеген белдерә торган Җәббар сүзе белән: Каза җитсә, бирә дикән Җәббар Ходай; Җәббар Хакъ рәвеше дә бар: Зар кылып мин җатырмын, Җәббар Хакъкай; Аллаһының бөеклеген, югаралыгын белдерү Аллаһы Тәгалә дип: Ул җәүһәр бер Аллаһы Тәгаләдән; Аллаһының кичерүче, гөнаһларны ярлыкаучы дигән сыйфатын белдерә торган Гаффар исеме белән: Гаффар Сез - йа Аллаһу. Әсәр эчтәлегендә Аллаһы Тәгаләнең аерым исемнәре махсус рәвештә төгәлләнеп тә бирелә. Мәсәлән, Аллаһы өчен үзгәреш юктыр дигән мәгънәне белдерә торган әл-Хаккъ гүзәл исемен Акмулла "белем, муллык, нигъмәт, юмартлык, шәфкать, рәхимлелек, бәрәкәт" төшенчәләренең атамасы булган фәйзь сүзе белән төгәлләп куллана: ...Һәр таләбдар бәндәсенең Фәйзе Хакъдан хаззы бар..., ягъни һәр тырышлык иясенең шәфкатьле, юмарт Хакътан өлеше бар. Яисә: Фәйзе Хакъ һәр мөмкинә гамь, шарт имәс Багдад, Хәләб ..., ягъни Рәхимле Хакъның рәхиме һәркемгә уртак: Багдадта яки Хәләбдә булу шарт түгел.

Хакъ сүзе Аллаһы Тәгаләнең бер гүзәл исеме булуы белән бергә, үзенең дөреслек, чын дигән мәгънәсе белән дә актив файдаланыла:

...Бәгъдәс - сәлам мин мосафир Акмулладан,

Тугъры әйтеп халыкга җазган хак мулладан...

Шулай итеп, татар, башкорт, казакъ халкының олуг мәгърифәтчесе Мифтахетдин Акмулла, үзенең әйтергә теләгән фикерен тасвирлап бирү максатыннан, классик иске татар теленең сәнгатьчә мөмкинлеген үзенчә баета һәм камилләштерә. Галимнәр билдергәнчә, бу юнәлештә аның данлыклы Эстәрлебаш мәдрәсәсендә күренекле шагыйрь Шәмсетдин Зәкидән белем алуының тәэсире дә зур була.

**Илида БӘШИРОВА,**
**филология фәннәре докторы**

---

*(Дәвамы. Башы газетабызның 3 август (№5) санында.)*

# КАПКА ТӨБЕНДӘ

(бәян-вәгазь)



Егет нәрсәдер әйтергә дип талпынып торган арада батып баручы кояш нурларында ялтыраган кырыс күзлек янә телгә килә:

- Кирәк булса эшләр, кирәк булса йоклар, сиңа отчёт биреп тормас!

Карчыгының кызып китә торган гадәтен белгәнгә, Гарәфетдин бабай сүзне башка якка бора:

- Их, җәмәгать, карале син аны, яңгырны мәйтәм, һаман яумый да яумый!

Күрше Мәхсүт абый да ике карчыкның әрепләшүенә нокта куярга омтылып, тизрәк сүзгә кушыла:

-Төптән уйлап карасаң, хәлебез чыннан да шәпләрдән түгел. Агач-үсемлекләр интегә, үзебезгә дә читен. Эсселек башланганнан бирле авылда суга кытлык, челтерәп аккан ике чишмә дә корып бетә язды - суы самавыр борыныннан кеби генә ага.

Мәрфуга апа бу юлы да кысылмыйча калмый:

- Моның тикле эсселектә дәвлини дә югары, башым әйләнә... Җитмәсә, нуябрьгә хәтле болай эссе булачак, дип сөйли кеше...

Бибинур түти башын горур күтәреп, кодагыена назлы, әмма үчле тавыш белән дәшә:

- Гыйнвар аена кадәр диючеләр дә бар!

Мәрфуга апа нык аптыраашта калып, үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрә:

- Әү!

- Авызың дәү! - дип бер дә исе китмәгәндәй әйтеп куя Бибинур. - Ирләр сөйләгәндә бераз булса да шул дәү авызыңны томалап торсаң, әй, рәхмәт укыр идем үзеңә!

Бу вакытта Гарәфетдин абыйларның капкасы янына ике өй аркылы яшәүче Илгиз абый килеп баса. Аксакалга хөрмәт белдерү йөзеннән ул, кулларын сузып, иң элек аның белән күрешә:

- Хәлләр ничек, бабай?

- Хәлләр изге, кодалар гына бизде! - дип бераз гына тавышын күтәреп җавап кайтара Гарәфетдин абый. - Карчыгым кодагыйга шушы 40 градуслы эсселек гыйнвар аена кадәр дәвам итәчәк дип юрый...

- Кит аннан! - дип шакката Илгиз абый. - Син, Бибинур түти, болай кеше куркытма! Башка алай юрама! Матри!

Яше алтмыштан узып та бер тапкыр да җомга намазына килеп карамаган Илгиз абыйның аракыга хирыс булуын белгән Гарәфетдин бабай күзләрен янә хәйләкәр кысып уйчан кыяфәт белән әкрен генә әйтә:

- Әй, җәмәгать, шулай гыйбадәтсез, бозыклык-гөнаһ кылып яшәсәң, тәмуг эссесендә берничә ай түгел - мәңгегә калуың ихтимал...

Яшьләргә хас булган кызыксыну белән Айдар көтелмәгән бер сорау бирә:

- Бабай, ә тәмугта температура ничә градус икән?

-Төгәл белмим, әмма бер хәдистә җәһәннәм уты җир утына караганда 70 мәртәбә кызурак, диелә. Анда эләгүдән Раббым Аллаһ Үзе сакласын!

- Алай булгач, хәзерге 40 градус әллә ни күп түгел дә икән, - дип үзенчә нәтиҗә ясый Айдар.

Моңарчы дәшмичә утырган тыйнаграк Хәерниса апа бу юлы сүзгә кушылырга була:

- Әле ярый 40 кына! Ә тагын да эссерәк - 50-60 градус булса, нишләр идек? Аллага шөкер, әле су бар! Ә су дөм бетсә, нишләмәк кирәк?

- Су дигәне бетә язды бит инде, җәмәгать! Ике айдан артык яңгыр юк! - дип борчылуын белдерә Мәхсүт ага. Карашын җиргә төбәп утырып торган Илгиз абый нәрсәдер исенә төшереп дәшә:

- Ә менә без яшь чакта яңгыр озаграк яумаса, чиләккә су тутырып урамга чыга идек тә шул суны беренче очраган кеше өстенә шәпләп ора идек. Тегесе хәлне аңлый, карышмый. Шуннан соң озак вакыт та үтми - яңгыр яварга тотына.

- Их, алай гына бик җайлы итеп яңгыр яудырып булса-а! - дип Айдар шиген белдергәч, Илгиз абый:

- Булыр иде дә ул, ләкин хәзер урамга чыгып кеше өстенә су тондырып карале син? Аты-юлы белән сүгенеп сиңа ыргылачак!

Мәхсүт абыйның исә бу хакта үз фикере:

- Әгәр син минем өстемә шулай су тондырганнан соң яңгыр явачагына төгәл гарантия бирә аласың икән - рәхим ит, мин рәхәтләнеп коенам. Ләкин бит син андый гарантия бирә алмыйсың!

Илгиз абый баш чүмечен кашып авыр сулап көрсенеп куя да, үзенә юнәлтелгән игътибардан тизрәк котылырга теләп, рәттән генә утыручы Тәгъзимә карчыкның терсәгенә төртеп сорау бирә:

- Әби, бабаеңа апираций булган икән, хәзер хәле ничегрәк?

Сиксәнгә 2-3 яшен генә тутырмаган Тәгъзимә апа, колагы катырак булганга, сорауны аңламый, әмма үзенә мөрәҗәгать итүләренә бик шатланып, Илгиз абыйга, урам яңгыратып, җавабын кайтара:

- Тешләремне дисеңме? Куйдырдым-куйдырдым, бәбкәем, әле узган атнада ук куйдырганыем, шуны да белмичә калдыңмыни?!

Әбинең тешләренә караганда, аның бабаеның хәлен белүне күпкә мөһимрәк санагангадыр, Илгиз абый уч төпләрен авызы янына рупор сыман куеп, Тәгъзимә апаның колагына ук соравын кычкырып кабатлый:

- Мин әйтәм, бабаеңның хәле ничек? Апирацийдән соң уңайланамы?!

- Ә-ә! Бабай дисеңме? Ие-ие, ул да бик сөенде яңа тешләр куйдырганыма! Ул ит дисеңме, кәбестәме - барысын рәхәтләнеп чәйним хәзер...

- И чукрак ... - дими түзми Илгиз абый. - Бабай ничек, дим, ба-ба-ай!!!

Тәгъзимә апа бераз кабаланып яулыгын кысыбрак бәйләп куя да, күршесенә текәлеп, борчулы тавыш белән сорый:

- Аба-ау, әллә синең дә тешләрен сызлыймы? "Ай-вай" дип сыкранып утыруыңны әйтәм...

Илгиз абый саңгырау карчык белән аралашуның файдасыз бер гамәл булуын аңлап, сорау бирүдән туктый.

Беразга гына урнашкан тынлыкны Мәрфуга апаның черелдек тавышы бүлә:

- Нинди хәл микән бу, әкәмәт! Җәй булгач, яңгыр яварга тиештер бит инде? Ә ул яумый да яумый!..

Аяз күктә күк күкрәгән шикелле, Бибинур түти каты, усал тавышы белән кодагыеның черелдәгәнен күмә:

- Яхшы булмас өчен бик әйбәт кенә! Әле ярый тамакларыбыз тук, ризыгыбыз бар дип шатланыйк! Тәмле ашыйбыз, тыныч йоклыйбыз, шөкер кылырлык түгелмени?!

- Ризык дигәннән, быел корылык булу сәбәпле, ипи бәясе нык күтәреләчәк диләр, - дип борчылуын белдерә Хәерниса апа.

*(Дәвамы газетабызның киләсе саннарында.)*

**Ришат КУРАМШИН,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Сәхәр тәмамлана | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 11.08.12 | 3:08 | 3:38 | 5:08 | 13:02 | 17:59 | 20:28 | 21:58 |
| Якшәмбе | 12.08.12 | 3:10 | 3:40 | 5:10 | 13:02 | 17:58 | 20:26 | 21:56 |
| Дүшәмбе | 13.08.12 | 3:12 | 3:42 | 5:12 | 13:02 | 17:56 | 20:23 | 21:53 |
| Сишәмбе | 14.08.12 | 3:14 | 3:44 | 5:14 | 13:02 | 17:55 | 20:21 | 21:51 |
| Чәршәмбе | 15.08.12 | 3:16 | 3:46 | 5:16 | 13:02 | 17:53 | 20:19 | 21:49 |
| Пәнҗешәмбе | 16.08.12 | 3:18 | 3:48 | 5:18 | 13:02 | 17:51 | 20:16 | 21:46 |
| Җомга | 17.08.12 | 3:20 | 3:50 | 5:20 | 13:02 | 17:50 | 20:14 | 21:44 |
| Шимбә | 18.08.12 | 3:22 | 3:52 | 5:22 | 13:02 | 17:49 | 20:12 | 21:42 |






# КҮҢЕЛЛӘРДӘ ИМАН НУРЫ

**Бик катлаулы чорда яшибез: телебез бетә, мәктәпләр ябыла, авыллар тарала. Әле ярый бүген халкыбызда дин бар, иман бар. Һәр төбәктә, һәр авылда мәчетләребез гөрләп эшләп тора.**

Авылыбызда дин тотарга бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Балаларның күбесе мәчеткә сабакка йөриләр. Нәкыйф хәзрәт һәм Маһинур абыстай әледән-әле дога конкурслары, төрле ашлар да үткәреп торалар. Март аенда узган конкурста күп укучылар, балалар бакчасында тәрбияләнүче кечкенә сабыйларга кадәр катнаштылар. Малайлар азан әйтсә, кызлар сүрәләр укыдылар. Катнашучылар берсе дә бүләксез калмады. Хәтта карап, тыңлап утыручыларга да Коръән аятьләре өләштеләр. Әле моның белән генә бетмәде. Хәзрәт белән абыстай җиңүче балаларны Мамадыш шәһәренә районкүләм дога укучылар конкурсына алып барды. Анда малайлар арасында Ислам Гобәйдуллин - беренче, Әдел Мусин икенче урынны яулады. Кызлар да призлы урыннарны читләргә бирмәде. Зөлфия Шәрифуллина, Гөлисә Абдуллина, Минзәлия Вәлиева җиңеп, күп бүләкләр белән кайттылар. Мәктәбебез директоры Фоат Насыйбуллин конкурста катнашкан һәм дин дәресләрен бер көн дә калдырмаган балаларга үзенең бүләген тәкъдим итте. Җәйге каникул чорында Изге Болгар шәһәренә экскурсиягә алып барырга сүз бирде. Һәм сүзендә торды да. Сәяхәт барышында укытучыларыбыз Болгар иле, ислам динен кабул итү тарихын сөйләп бардылар. Моннан 20 ел элек әнием укучы буларак үткән юлны, Фоат абый җитәкчелегендә миңа да кабат үтәргә насыйп булды. Ак мәчет һәм дөньядагы иң зур Коръән китабы күңелләребездә тирән тәэсир калдырды.

Хәзер иң изге айларның берсе булган рамазан ае бара. "Мәчетебездә ифтар мәҗлесе булачак", - дигән хәбәр ишетелүгә, укытучыларыбыз тиз генә җыелышып, мәчетнең капка-коймаларын буяды. Мәҗлескә күп авылдашларыбыз үз өлешләрен керттеләр. Казаннан кайткан Гөлгенә Шиһапова тәкә суйдырды, Рәсимә Вәлиева токмач кисеп китерде. Табын әзерләү, аш һәм бәлеш пешерү Тәнзилә апага йөкләнде. Күпләр акчалата ярдәм күрсәтте, әбиләр күчтәнәчләр белән килде. Бик бай, бәрәкәтле табын хасил булды. Бөтен авыл җыелышып авыз ачтык, вәгазьләр, Коръән аятьләре тыңладык. Мәҗлес бик җанлы, тирән эчтәлекле узды. Күңелләр сафланып калды.

**Ралия МУСИНА,**
**Мамадыш районы Түбән Яке урта мәктәбенең VI сыйныф укучысы**


## Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

***Мамадыш мәдрәсәсе 2012-2013 нче уку елына***
***УКЫРГА ЧАКЫРА***

***ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе 2012-2013 нче уку елына шәкертләр туплый.***

Белгечләр әзерләү көндезге, кичке һәм читтән торып уку рәвешендә алып барыла.

Көндезге бүлеккә яше ундүрттән дә ким булмаган егетләр кабул ителә. Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә өч тапкыр ашау-эчү белән тәэмин ителәләр. Уку вакыты - өч ел. Урта белем алу икенче санлы лицей нигезендә алып барыла.

Кичке һәм читтән торып уку бүлегенә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган. Уку вакыты - дүрт ел.

Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә.

**БЕЗНЕҢ АДРЕС:** ***Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М.Җәлил урамы, 8/28 нче йорт.***
***Телефоннар: 8 (85563) 3-19-17, 89172802391.***


# Миңа ирем белән мөселманнар булмаган мохиттә яшәве кыен...

**Мин ислам динендә - бер, ә ирем ике елдан артык. Безнең кечкенә ике балабыз бар. Минем күңелемне бимазалаган нәрсә шуннан гыйбарәт ки, безнең якыннарыбыз (әти-әнием һәм туганнарыбыз) - христианнар һәм алар безнең мөселман булуыбызга бик нык каршы торалар: сездә "заморочки" (кешенең гадәти булмаган характер сыйфаты, үзенчәлек), чөнки хәзер XXI гасыр һәм башка мөселманнар да гадәти кешеләр кебек үк яши, дип әйтәләр. Мөселманнарга карата даими рәвештә ачу һәм нәфрәт сүзләре кулланалар, күп очракта бу телевидение яңалыкларына нигезләнеп әйтелә.**

*Бүген мин, гомумән, тәтәйдән "динне чит планеталарда яшәүчеләр уйлап тапкан" дигән сүз ишеттем. Шуннан соң минем аңа шактый озак вакыт бернәрсә дә әйтәсем һәм карышып торасым килмәде, ничектер телем әйләнмәде, аңа барын да мораль һәм матди (материаль) яктан ярдәм итәргә, булышырга тырыштым, беркайчан да явызлык теләмәдем, һәм мин шулай тәрбияләнгән дә инде, "артык сүзләр сөйли алмыйм". Әмма шушы көннәрдә түзмәдем, динебезне, пәйгамбәребез Мөхәммәдне (сгв) яклый һәм үземнең тормышыма якын булган нәрсәләр сайлавымны аңлата башладым. Әмма минем барлык аңлатмаларыма җавап йөзеннән мине үк гаеплегә чыгарып калдырдылар, ә иремне исә ул мине әнием белән читләштергәнгә чыгарып, безне сектада дип, күңелгә ятышсыз сүзләр сөйли башладылар.*

*Зинһар өчен, ярдәм итегез, безгә нишләргә?! Ирем: "Безгә Аллаһ ризалыгы өчен сабыр итәргә, аларны гафу итәргә кирәк", - ди. Әмма бу бик тә читен бит! Миңа безнең сектада булмавыбызны, үзебезнең гаиләбез өчен бары яхшысын гына теләвебезне якыннарыбызга ничек җиткерергә? Безнең хәзер нәрсә эшләвебез һәм үлгәннән соң кая барачагыбыз турында уйланырга кирәклекне ничек аңлатырга? Һәм, гомумән, бу мөмкин эшме? Яки барысын да Аллаһның ихтыярына гына калдырырга кирәкме?*

*Исемемне күрсәтәсем килми*

**Сезнең соравыгызга Татарстанның көнчыгыш төбәге казые, Әлмәт районы һәм шәһәре имам-мөхтәсибе Рафикъ хәзрәт Миңнәхмәтов җавап бирә:**

- Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди (мәгънәсе): "Раббың бары тик үзенә генә гыйбадәт кылуыгызны, ата-анагызга да игелекле булуыгызны катгый рәвештә боерды. Аларның берсе яки икесе дә сезнең янда картайса, сак булыгыз, аларга "уф" (туйдым сездән) димәгез; аларны битәрләмәгез; икесенә дә яхшы мөгамәләдә булыгыз, алар белән йомшак сөйләшегез" ("Исра (Төнге йөрү, Ягъкуб угыллары) сүрәсе", 23 нче аять).

Шуңа игътибар итегез: әти-әниләргә әшәке, тупас сүзләр әйтүне яки аларга карата начар мөнәсәбәттә булуны тыеп, Аллаһы Тәгалә әти-әнисе мөселман яки мөселман булмаганнар арасына аермалар куймый. Үзеңнең әти-әниеңне хөрмәт итү һәм аларга карата яхшы мөнәсәбәттә булу сорала, хәтта алар бүтән динне тотсалар һәм бөтенләй дәһри (атеист) булсалар да. Моннан тыш, кемнең бу дөньядан кем булып китәчәген берәү дә белми бит әле, бәлки алар, мондый очракларда еш кына күзәтелгәнчә, ислам динен кабул итәрләр! Әлбәттә, әти-әниләр авызыннан чыккан кяферлекне тыңларга кирәкми, ә аларга теге яки бу хәлне ягымлы итеп, түбәнчелек белән аңлату тиешле. Сез аларның ата-ана тойгылары белән "уйна"масагыз, алар ягыннан җавап алай ук тискәре булмас.

Аллаһ илчесе (сгв) Үзенең сәхабәсе Мөгазь бине Җәбәлүгә (Аллаһ аннан разый булса иде) болай дигән: "Аллаһ синең аркылы бер генә кешене булса да хакыйкый юлга үгетләсә, бу синең өчен бөтен дөньяга һәм андагы барлык нәрсәләргә караганда да яхшырак!" Шуңа күрә эш үзагымга куелмаска тиеш, дигәнне башыгызга сеңдерегез, Аллаһ туры юлга Үзе алып керер, үз алдыгызга әти-әниләрегезне Исламга йөз белән борып, аларны да дингә алып килү бурычын куегыз. Кагыйдә буларак, бүтән диндәгеләрнең мөселманнарга тискәре мөнәсәбәте Ислам турындагы ялгыш күзаллаулары, югарыда үзегез үк әйткәнчә, еш кына массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан максатчан рәвештә куелуы белән бәйле. Алардагы ялгыш күзаллауларны бетерү өчен, гомумкешелек һәм ислам кыйммәтләре арасына параллель уздырыгыз, мисал өчен, өлкәннәргә карата хөрмәт, Исламда чит тормыш, намус, милек кыйммәтләре һ. б. турында сөйләгез. Әти-әниләрегезгә фәнни яктан нигезләнгән әдәбият, әйтик, "Божественные чудеса" яки төрек философы Аднан Октарның (Һарун Яхъя) китапларын, шулай ук әлеге китапларга нигезләнеп эшләнгән фильмнарны бүләк итегез.



Гадәттә, кешеләр синең сүзләреңә карамый, ә синең әхлагыңа, тәртибеңә карый. Беренче мөселманнар Пәйгамбәребезнең (сгв) сүзләренә генә карап түгел, ә гүзәл холкын, йомшаклыгын, юмартлыгын күреп ислам диненә кергәннәр. Шулай ук онытмаска кирәк - бер Аллаһ кына туры юлга кертүче, Аллаһтан аларны туры юлга кертүен сорап дога кылып торыгыз. Нәтиҗә ясап, сезгә тагын бер мәртәбә әти-әниләрегез белән киңәшләшергә һәм үзегезнең дөрес, яхшы мөнәсәбәтегез белән аларны Исламга дәгъват кылырга киңәш итәр идем.


**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 6 (149) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9411.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 9 август көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**